35. «Җыелышлар, митинглар, демонстрацияләр, урам йөрешләре һәм пикетлар турында» Федераль законга үзгәрешләр кертү хакында» 388351-7 номерлы федераль закон проекты турында (тиз корыла торган җыю-сүтү конструкциясен кулланып гавами чаралар үткәрү өлешендә).

36. «Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексының 20.3 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» 390402-7 номерлы федераль закон проекты турында (пропаганда билгеләре булмау шарты белән фән, әдәбият, сәнгать әсәрләрендә, шулай ук мәгълүмат бирү, уку-укыту һәм агарту максатларында нацист символикасын яисә атрибутикасын куллану очраклары өчен административ җаваплылыкны бетерү өлешендә).

37. «Россия Федерациясендә чит ил гражданнарының хокукый хәле турында» Федераль законның 5 һәм 9 статьяларына үзгәрешләр кертү хакында» 393272-7 номерлы федераль закон проекты турында (Кырым АССР территориясеннән законсыз депортациягә дучар ителгән затларның Россия Федерациясе территориясендә вакытлыча булу тәртибен төгәлләштерү өлешендә).

38. «Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексына үзгәрешләр кертү хакында» 395252-7 номерлы федераль закон проекты турында (насвай һәм снюс саткан өчен җаваплылыкны арттыру өлешендә).

39. «Гражданнар оборонасы турында» Федераль законның 10 статьясына үзгәреш кертү хакында» 399763-7 номерлы федераль закон проекты турында (гражданнар оборонасы өлкәсендәге мәсьәләләрне хәл итүдә гражданнарның җирле үзидарә органнарына ярдәм итү тәртибен җайга салу).

40. «Россия Федерациясе гражданлыгы турында» Федераль законның 14 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» 403168-7 номерлы федераль закон проекты турында (Россия Федерациясе гражданлыгына гадиләштерелгән тәртиптә кабул

итү хакындагы гариза белән мөрәҗәгать итәргә хокуклы затлар исемлеген киңәйтү өлешендә).

41. «Россия Федерациясеннән чыгу һәм Россия Федерациясенә керү тәртибе турында» Федераль законга, «Россия Федерациясенең аерым закон актларына Калининград өлкәсен социаль-икътисадый үстерү мәсьәләләре буенча үзгәрешләр кертү турында» Федераль законның 2 статьясына һәм «Россия Федерациясендә чит ил гражданнарының хокукый хәле турында» Федераль законның 11 статьясына Ерак Көнчыгыш федераль округы территориясендә урнашкан Россия Федерациясенең дәүләт чиге аша кертүнең һава пунктлары территориясендә чит ил гражданнарының электрон визалар буенча керүенең гадиләштерелгән тәртибен тарату өлешендә үзгәрешләр кертү хакында» 405915-7 номерлы федераль закон проекты хакында.

42. «Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексына эчәргә яраклы су һәм хуҗалык-көнкүреш өчен су белән тәэмин итү чыганакларының санитария зонасыннан файдаланудагы хокук бозулар өчен җаваплылыкны катгыйландыру өлешендә үзгәрешләр кертү хакында» 412455-7 номерлы федераль закон проекты турында.

43. «Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексына үзгәрешләр кертү хакында» 416226-7 номерлы федераль закон проекты турында (инфраструктура челтәрләренә рөхсәтсез яңадан тоташкан һәм энергетика ресурсларыннан рөхсәтсез яңадан файдаланган өчен административ җаваплылыкны көчәйтү өлешендә).

44. «Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексының 12.10 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» 416294-7 номерлы федераль закон проекты турында (тимер юллар аша хәрәкәт итү кагыйдәләрен бозган өчен административ җаваплылыкны көчәйтү өлешендә).

45. «Хәрби бурыч һәм хәрби хезмәт турында» Федераль законның 10 статьясына үзгәреш кертү хакында» 421922-7 номерлы федераль закон проекты турында (персональ электрон карта кертү мәсьәләсе буенча).

46. «Россия Федерациясе Хезмәт кодексының 193 статьясына үзгәреш кертү турында» 430596-7 номерлы федераль закон проекты турында (коррупциячел хокук бозулар өчен җәзалар бирүне куллану өчен бердәм вакыт узу срогын билгеләү өлешендә).

47. «Россия Федерациясенең аерым закон актларына коррупциягә каршы тору турындагы Россия Федерациясе законнары үтәлешен тикшереп торуны камилләштерү максатларында үзгәрешләр кертү хакында» 430594-7 номерлы федераль закон проекты турында.



48. «Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексының 14.28 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» федераль закон проектын Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасына кертү буенча Ленинград өлкәсе Закон чыгару Собраниесенең закон чыгару инициативасы турында.

49. «Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексына һава транспортында хокукка каршы гамәлләр кылган өчен административ җаваплылыкны көчәйтү өлешендә үзгәрешләр кертү хакында» 426908-7 номерлы федераль закон проекты турында.

50. «Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексына үзгәрешләр кертү хакында» 427198-7 номерлы федераль закон проекты турында (дәүләт оборона заказы буенча дәүләт контракты шартларын бозган өчен административ җаваплылыкны көчәйтү хакында).

51. «Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексының 7.1 статьясына үзгәреш кертү хакында» 405757-7 номерлы федераль закон проекты турында (җир кишәрлеген ихтыяри алган өчен җаваплылыкны арттыру өлешендә).

52. «Россия Федерациясендә гомуми юрисдикциядәге федераль судларының присяжный утырышчылары турында» Федераль законның 6 статьясына үзгәреш кертү хакында» 397356-7 номерлы федераль закон проекты турында (присяжный утырышчыларга кандидатлар исемлекләрен төзү өчен мәгълүмат бирү өлешендә).

53. «Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексына үзгәрешләр кертү хакында» 430595-7 номерлы федераль закон проекты турында (юридик затларны административ җаваплылыктан азат итү шартларын һәм эш буенча гамәл башкаруны тәэмин итүнең яңа чарасын билгеләү турында).

54. «Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексының 14.1 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» 414542-7 номерлы федераль закон проекты турында (эшкуарлык эшчәнлеген законсыз гамәлгә ашыручы затларның җаваплылыгын арттыру өлешендә).

55. Төрлесеннән.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе**
**Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2018 елның 25 апреле
№ 2252-V ДС

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

### 287. Татарстан Республикасы җәмәгать судьяларын сайлау турында

Татарстан Республикасы Конституциясенең 75 статьясы нигезендә Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә:**

1. Татарстан Республикасы җәмәгать судьялары итеп биш елга түбәндәгеләрне сайларга:

Татарстан Республикасы Зәй суд районы буенча:
1 нче суд участогына – Сөләйманов Айдар Мансур улын;

Татарстан Республикасы Казан шәһәренең Идел буе суд районы буенча:
10 нчы суд участогына – Грицков Евгений Вячеславовичны;

Татарстан Республикасы Казан шәһәренең Совет суд районы буенча:
4 нче суд участогына – Анисимов Роман Олеговичны;

Татарстан Республикасы Чистай суд районы буенча:
4 нче суд участогына – Кәримов Радик Хикмәтулла улын.

2. Әлеге карарның 1 пункты нигезендә сайланган Татарстан Республикасы җәмәгать судьясы Анисимов Роман Олеговичның вәкаләтләре чоры 2018 елның 21 маеннан башлана.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе**
**Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2018 елның 25 апреле
№ 2253-V ДС



## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

### 288. Татарстан Республикасы җәмәгать судьялары вазыйфаларын башкару турында

«Россия Федерациясендә судьялар статусы турында» Россия Федерациясе Законының $7^1$ статьясы һәм «Татарстан Республикасы җәмәгать судьялары турында» Татарстан Республикасы Законының 8 статьясы нигезендә Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә:**

1. Татарстан Республикасы Казан шәһәренең Киров суд районы буенча 1 нче суд участогы җәмәгать судьясы вазыйфаларын башкаруны бер елга отставкадагы судья Садриева Марина Александровнага йөкләргә.

2. Татарстан Республикасы Казан шәһәренең Идел буе суд районы буенча 3 нче суд участогы җәмәгать судьясы вазыйфаларын башкаруны бер елга отставкадагы судья Ганиева Ландыш Алферт кызына йөкләргә.

3. Татарстан Республикасы Чистай суд районы буенча 2 нче суд участогы җәмәгать судьясы вазыйфаларын башкаруны бер елга отставкадагы судья Әхәтов Газинур Зөфәр улына йөкләргә.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе**
**Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2018 елның 25 апреле
№ 2254-V ДС

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

### 289. «Россия Федерациясендә мәгариф турында» Федераль законга үзгәрешләр кертү хакында» 438863-7 номерлы федераль закон проекты буенча Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасы Рәисе В.В. Володинга Татарстан Республикасы Дәүләт Советы мөрәҗәгате турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә:**

1. «Россия Федерациясендә мәгариф турында» Федераль законга үзгәрешләр кертү хакында» 438863-7 номерлы федераль закон проекты буенча Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасы Рәисе В.В. Володинга Татарстан Республикасы Дәүләт Советы мөрәҗәгатен хупларга һәм аны Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасына җибәрергә (кушымта итеп бирелә).

2. Әлеге карарны Россия Федерациясе республикалары дәүләт хакимиятенең закон чыгару (вәкиллекле) органнарына җибәрергә.

3. Әлеге карарны республика массакүләм мәгълүмат чараларында бастырып чыгарырга.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе**
**Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2018 елның 25 апреле
№ 2255-V ДС

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советының «Россия Федерациясендә мәгариф турында» Федераль законга үзгәрешләр кертү хакында» 438863-7 номерлы федераль закон проекты буенча Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасы Рәисе В.В. Володинга мөрәҗәгате турында**

Хөрмәтле Вячеслав Викторович!

Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасына «Россия Федерациясендә мәгариф турында» Федераль законга үзгәрешләр кертү хакында» 438863-7 номерлы федераль закон проекты кертелде. Закон проектында Россия Федерациясе республикаларының дәүләт телләрен укыту һәм өйрәнү – ихтыярый нигездә, ә туган телләрне өйрәнү укучыларның һәм аларның ата-аналарының ихтыяҗларын исәпкә алып гамәлгә ашырыла дип билгеләнә.

Россия Федерациясе республикаларының дәүләт телләрен билгеләү хокукы аларның Россия Федерациясенең башка субъектларыннан үзгә булган конституциячел-хокукый статус үзенчәлеге булып тора. Республикаларның дәүләт телләре аларның дәүләт хакимияте органнарында, җирле үзидарә органнарында, дәүләт учреждениеләрендә Россия Федерациясе



дәүләт теле белән беррәттән кулланыла (Россия Федерациясе Конституциясенең 68 статьясындагы 2 өлеше).

Әлеге конституциячел күрсәтмәләр нигезендә Россия Федерациясе законнары республикаларның дәүләт телләрен төрле иҗтимагый мөнәсәбәтләрдә куллануны гарантияли.

Россия Федерациясе Конституция Судының 2004 елның 16 ноябрендәге 16-П номерлы карарында чагылыш тапкан хокукый позициясеннән аңлашылганча, төп гомуми белем алганда республика дәүләт телен өйрәнү – барлык рәсми мөнәсәбәтләр өлкәсендә аның кулланылышын тәэмин итү чараларының берсе булып тора.

Россия Федерациясе республикалары дәүләт телләрен тиешенчә өйрәнүне юкка чыгару, һичшиксез, әлеге телләрнең дәүләт теле буларак эшчәнлеге бозылуга китерәчәк, шулай ук ул Россия Федерациясендә һәр гражданның Россия Федерациясе Конституциясендә каралган барлык хокукларга һәм ирекләргә ия булуы, бертигез бурычларны үтәве турында шәхеснең статусын билгели торган төп нигезләмәләренә туры килми (6 статьяның 2 өлеше).

Белем бирү мәсьәләләрен хәл итүдә катнашучылар тарафыннан Россия Федерациясе халыклары телләрен өйрәнүне төп мәгариф программасының вариатив өлешенә күчерергә омтылу шулай ук тирән борчу тудыра. Россия Федерациясе Конституциясенең 68 статьясындагы 3 өлеше нигезендә Россия Федерациясе үзенең барлык халыкларына туган телләрен саклау, өйрәнү һәм үстерү өчен шартлар тудыру хокукын гарантияли. Хәзерге вакытта федераль законнар һәм федераль дәүләт мәгариф стандартлары белән Россия Федерациясе халыклары телләре арасыннан булган туган телне укыту һәм өйрәтү мөмкинлеге тәэмин ителә. Туган тел рус теле һәм әдәбияты, чит телләр, математика һәм башка предметлар белән беррәттән мәҗбүри укытыла торган предметлар исәбенә керә.

Тәкъдим ителә торган үзгәрешләр мәгариф өлкәсендә дәүләт сәясәте принципларына туры килми һәм белем бирүнең асылын чагылдырган таләпкә – кешеләр, халыклар арасында милләтенә, этник мөнәсәбәтенә карамастан үзара аңлашуга һәм хезмәттәшлеккә ярдәм итү таләбенә җавап бирми («Россия Федерациясендә мәгариф турында» Федераль законның 12 статьясындагы 3 статьясының 1 өлеше, 12 статьясындагы 1 өлеше).

Дәүләт мәгариф системасы яшь буынның һәрьяклап үсеше, Россия Федерациясе күпмилләтле халкының милли күптөрлелеген һәм тел мирасын саклап калу һәм үстерү зарурлыгыннан чыгып эш итәргә тиеш. Дәүләт телләрен һәм Россия Федерациясе халыклары телләрен факультатив өйрәнү телләрне

гамәлдә куллануны көнкүрештә аралашу теле итеп калдыруга һәм киләчәктә милли үзаңның югалуына китерәчәк.

Россия Федерациясе халыклары телләрен өйрәнү кебек үзенчәлекле, һәрьяклап төгәллек таләп итә торган милләтара мөнәсәбәтләр өлкәсе, Россия халыклары мәнфәгатьләрен исәпкә алып, төптән уйланылган карарлар кабул итүне күздә тота, алар безнең күпмилләтле Ватаныбызны алга таба ныгытуга хезмәт итәчәк.

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы мәгариф программасының мәҗбүри өлешендә Россиянең бөтен халыклары өчен туган телне өйрәнү хокукын саклап калырга, шулай ук республика дәүләт телләрен укыту һәм өйрәнүне оештыруда билгесезлекне бетерергә кирәк, федераль дәүләт мәгариф стандартларында дәүләт телләрен өйрәнүнең билгеләнүен мәҗбүри дип саный.

Киң җәмәгатьчелектә тискәре резонанска юл куймау максатларында әлеге закон проекты Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасына карауга кертелгәнче Россия Федерациясе республикаларында һәм автономияләрендә тикшерелергә тиеш.

Сезгә мөрәҗәгать итеп, хөрмәтле Вячеслав Викторович, Россия Федерациясе гражданнарының тел һәм мәгариф сәясәте өлкәсендә гамәлгә ашырыла торган конституциячел хокуклары һичшиксез үтәлер дигән ышаныч белдерәбез.

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

### 290. «Татарстан Республикасы Сайлау кодексына һәм Татарстан Республикасының аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 385-5 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты хакында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә:**

1. «Татарстан Республикасы Сайлау кодексына һәм Татарстан Республикасының аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 385-5 номерлы Татарстан Республикасы законы проектын икенче укылышта кабул итәргә.

2. Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Дәүләт корылышы һәм җирле үзидарә комитеты күрсәтелгән закон проектын эшләп бетерергә һәм Татарстан Республикасы Дәүләт Советына өченче укылышта карауга кертергә тиеш.



**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе**
**Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2018 елның 25 апреле
№ 2256-V ДС

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

### 291. «Татарстан Республикасында гражданнар мөрәҗәгатьләре турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 427-5 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә:**

«Татарстан Республикасында гражданнар мөрәҗәгатьләре турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 427-5 номерлы Татарстан Республикасы законы проектын икенче укылышта кабул итәргә.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе**
**Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2018 елның 25 апреле
№ 2257-V ДС

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

### 292. «Татарстан Республикасында гражданнар мөрәҗәгатьләре турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законы турында (427-5 номерлы проект)

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә:**

1. «Татарстан Республикасында гражданнар мөрәҗәгатьләре турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законын (427-5 номерлы проект) кабул итәргә.

2. Күрсәтелгән законны Татарстан Республикасы Президентына җибәрергә.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе**
**Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2018 елның 25 апреле
№ 2258-V ДС

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

### 293. «Татарстан Республикасында шәһәр төзелеше эшчәнлеге турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 432-5 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә:**

«Татарстан Республикасында шәһәр төзелеше эшчәнлеге турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 432-5 номерлы Татарстан Республикасы законы проектын икенче укылышта кабул итәргә.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе**
**Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2018 елның 25 апреле
№ 2259-V ДС



## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

### 294. «Татарстан Республикасында шәһәр төзелеше эшчәнлеге турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законы турында (432-5 номерлы проект)

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә:**

1. «Татарстан Республикасында шәһәр төзелеше эшчәнлеге турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законын (432-5 номерлы проект) кабул итәргә.

2. Күрсәтелгән законны Татарстан Республикасы Президентына җибәрергә.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе**
**Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2018 елның 25 апреле
№ 2260-V ДС

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

### 295. «Татарстан Республикасында торак төзелеше үсешенә дәүләт ярдәме турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 439-5 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә:**

«Татарстан Республикасында торак төзелеше үсешенә дәүләт ярдәме турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 439-5 номерлы Татарстан Республикасы законы проектын икенче укылышта кабул итәргә.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе**
**Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2018 елның 25 апреле
№ 2261-V ДС

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

### 296. «Татарстан Республикасында торак төзелеше үсешенә дәүләт ярдәме турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законы турында (439-5 номерлы проект)

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә:**

1. «Татарстан Республикасында торак төзелеше үсешенә дәүләт ярдәме турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законын (439-5 номерлы проект) кабул итәргә.

2. Күрсәтелгән законны Татарстан Республикасы Президентына җибәрергә.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе**
**Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2018 елның 25 апреле
№ 2262-V ДС

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

### 297. «Татарстан Республикасында күпфатирлы йортларда гомуми мөлкәткә капиталь ремонт ясауны оештыру турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 444-5 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә:**

«Татарстан Республикасында күпфатирлы йортларда гомуми мөлкәткә капиталь ремонт ясауны оештыру турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 444-5 номерлы Татарстан Республикасы законы проектын икенче укылышта кабул итәргә.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе**
**Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2018 елның 25 апреле
№ 2263-V ДС



## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

### 298. «Татарстан Республикасында күпфатирлы йортларда гомуми мөлкәткә капиталь ремонт ясауны оештыру турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законы турында (444-5 номерлы проект)

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә:**

1. «Татарстан Республикасында күпфатирлы йортларда гомуми мөлкәткә капиталь ремонт ясауны оештыру турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законын (444-5 номерлы проект) кабул итәргә.

2. Күрсәтелгән законны Татарстан Республикасы Президентына җибәрергә.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе**
**Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2018 елның 25 апреле
№ 2264-V ДС

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

### 299. «Татарстан Республикасында җәмәгать тәртибен саклауда гражданнарның катнашуы турында» Татарстан Республикасы Законының 4 һәм 8 статьяларына үзгәрешләр кертү хакында» 435-5 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә:**

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутаты Р.Г. Ногманов тарафыннан кертелгән «Татарстан Республикасында җәмәгать тәртибен саклауда гражданнарның катнашуы турында» Татарстан Республикасы Законының 4 һәм 8 статьяларына үзгәрешләр кертү хакында» 435-5 номерлы Татарстан Республикасы законы проектын беренче укылышта кабул итәргә.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе**
**Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2018 елның 25 апреле
№ 2265-V ДС

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

### 300. «Татарстан Республикасында җәмәгать тәртибен саклауда гражданнарның катнашуы турында» Татарстан Республикасы Законының 4 һәм 8 статьяларына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законы турында (435-5 номерлы проект)

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә:**

1. «Татарстан Республикасында җәмәгать тәртибен саклауда гражданнарның катнашуы турында» Татарстан Республикасы Законының 4 һәм 8 статьяларына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законын (435-5 номерлы проект) кабул итәргә.

2. Күрсәтелгән законны Татарстан Республикасы Президентына җибәрергә.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе**
**Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2018 елның 25 апреле
№ 2266-V ДС

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

### 301. «Янгын куркынычсызлыгы турында» Татарстан Республикасы Законының 9 һәм 10 статьяларына үзгәрешләр кертү хакында» 448-5 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә:**

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан кертелгән «Янгын куркынычсызлыгы турында» Татарстан Республикасы Законының 9 һәм 10 статьяларына үзгәрешләр кертү хакында» 448-5 номерлы Татарстан Республикасы законы проектын икенче укылышта кабул итәргә.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе**
**Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2018 елның 25 апреле
№ 2267-V ДС



## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

### 302. «Янгын куркынычсызлыгы турында» Татарстан Республикасы Законының 9 һәм 10 статьяларына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законы турында (448-5 номерлы проект)

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә:**

1. «Янгын куркынычсызлыгы турында» Татарстан Республикасы Законының 9 һәм 10 статьяларына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законын (448-5 номерлы проект) кабул итәргә.

2. Күрсәтелгән законны Татарстан Республикасы Президентына җибәрергә.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе**
**Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2018 елның 25 апреле
№ 2268-V ДС

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

### 303. «Татарстан Республикасы дәүләт бүләкләре турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 449-5 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә:**

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутаты А.Г. Хәбибуллин тарафыннан кертелгән «Татарстан Республикасы дәүләт бүләкләре турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 449-5 номерлы Татарстан Республикасы законы проектын беренче укылышта кабул итәргә.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе**
**Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2018 елның 25 апреле
№ 2269-V ДС

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

### 304. «Татарстан Республикасы дәүләт бүләкләре турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законы турында (449-5 номерлы проект)

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә:**

1. «Татарстан Республикасы дәүләт бүләкләре турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законын (449-5 номерлы проект) кабул итәргә.

2. Күрсәтелгән законны Татарстан Республикасы Президентына җибәрергә.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе**
**Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2018 елның 25 апреле
№ 2270-V ДС

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

### 305. «Татарстан Республикасының монопрофильле муниципаль берәмлекләре (моношәһәрләре) территорияләрендә төзелгән социаль-икътисадый үсеше алдан билгеләнә торган территорияләр резидентлары өчен оешмалар табышына салым буенча салым ставкасын билгеләү турында» Татарстан Республикасы Законының 1 статьясына үзгәреш кертү хакында» 440-5 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә:**

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутаты С.В. Раковец тарафыннан кертелгән «Татарстан Республикасының монопрофильле муниципаль берәмлекләре (моношәһәрләре) территорияләрендә төзелгән социаль-икътисадый үсеше алдан билгеләнә торган территорияләр резидентлары өчен оешмалар табышына салым буенча салым ставкасын билгеләү турында» Татарстан Республикасы Законының 1 статьясына үзгәреш кертү хакында» 440-5 номерлы Татарстан Республикасы законы проектын беренче укылышта кабул итәргә.



**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе**
**Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2018 елның 25 апреле
№ 2271-V ДС

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

### 306. «Татарстан Республикасының монопрофильле муниципаль берәмлекләре (моношәһәрләре) территорияләрендә төзелгән социаль-икътисадый үсеше алдан билгеләнә торган территорияләр резидентлары өчен оешмалар табышына салым буенча салым ставкасын билгеләү турында» Татарстан Республикасы Законының 1 статьясына үзгәреш кертү хакында» Татарстан Республикасы законы турында (440-5 номерлы проект)

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә:**

1. «Татарстан Республикасының монопрофильле муниципаль берәмлекләре (моношәһәрләре) территорияләрендә төзелгән социаль-икътисадый үсеше алдан билгеләнә торган территорияләр резидентлары өчен оешмалар табышына салым буенча салым ставкасын билгеләү турында» Татарстан Республикасы Законының 1 статьясына үзгәреш кертү хакында» Татарстан Республикасы законын (440-5 номерлы проект) кабул итәргә.

2. Күрсәтелгән законны Татарстан Республикасы Президентына җибәрергә.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе**
**Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2018 елның 25 апреле
№ 2272-V ДС

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

## 307. «Татарстан Республикасы Җир кодексының 32[1] статьясына үзгәрешләр кертү турында» 442-5 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты хакында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә:**

1. Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутатлары Т.Г. Һадиев һәм Р.Р. Гайзатуллин тарафыннан кертелгән «Татарстан Республикасы Җир кодексының 32[1] статьясына үзгәрешләр кертү турында» 442-5 номерлы Татарстан Республикасы законы проектын беренче укылышта кабул итәргә.

2. Күрсәтелгән закон проектына төзәтмәләр 2018 елның 25 маена кадәр Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Экология, табигатьтән файдалану, агросәнәгать һәм азык-төлек сәясәте комитетына кертелә дип билгеләргә.

3. Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Экология, табигатьтән файдалану, агросәнәгать һәм азык-төлек сәясәте комитеты әлеге закон проектын, кергән төзәтмәләрне исәпкә алып, 2018 елның 25 июненә кадәр эшләп бетерергә һәм Татарстан Республикасы Дәүләт Советына икенче укылышта карауга кертергә тиеш.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе**
**Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2018 елның 25 апреле
№ 2273-V ДС

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

## 308. «Татарстан Республикасы Экология кодексының 8 статьясына үзгәрешләр кертү турында» 446-5 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты хакында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә:**

1. Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутатлары Т.Г. Һадиев һәм Р.Р. Гайзатуллин тарафыннан кертелгән «Татарстан Республикасы Экология кодексының 8 статьясына үзгәрешләр кертү турында» 446-5 номерлы Татарстан Республикасы законы проектын беренче укылышта кабул итәргә.



2. Күрсәтелгән закон проектына төзәтмәләр 2018 елның 25 маена кадәр Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Экология, табигатьтән файдалану, агросәнәгать һәм азык-төлек сәясәте комитетына кертелә дип билгеләргә.

3. Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Экология, табигатьтән файдалану, агросәнәгать һәм азык-төлек сәясәте комитеты әлеге закон проектын, кергән төзәтмәләрне исәпкә алып, 2018 елның 25 июненә кадәр эшләп бетерергә һәм Татарстан Республикасы Дәүләт Советына икенче укылышта карауга кертергә тиеш.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе**
**Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2018 елның 25 апреле
№ 2274-V ДС

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

## 309. «Татарстан Республикасы Экология кодексына үзгәрешләр кертү турында» 400-5 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты хакында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә:**

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутаты А.В. Прокофьев тарафыннан кертелгән «Татарстан Республикасы Экология кодексына үзгәрешләр кертү турында» 400-5 номерлы Татарстан Республикасы законы проектын кире кагарга.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе**
**Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2018 елның 25 апреле
№ 2275-V ДС

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

**310. «Татарстан Республикасында халыкка адреслы социаль ярдәм күрсәтү турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 450-5 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында**

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә:**

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан кертелгән «Татарстан Республикасында халыкка адреслы социаль ярдәм күрсәтү турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 450-5 номерлы Татарстан Республикасы законы проектын беренче укылышта кабул итәргә.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе**
**Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2018 елның 25 апреле
№ 2276-V ДС

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

**311. «Татарстан Республикасында халыкка адреслы социаль ярдәм күрсәтү турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законы турында (450-5 номерлы проект)**

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә:**

1. «Татарстан Республикасында халыкка адреслы социаль ярдәм күрсәтү турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законын (450-5 номерлы проект) кабул итәргә.

2. Күрсәтелгән законны Татарстан Республикасы Президентына җибәрергә.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе**
**Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2018 елның 25 апреле
№ 2277-V ДС



ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

**312. «Татарстан Республикасында җан башына һәм халыкның төп социаль-демографик төркемнәре буенча яшәү минимумы күләмен билгеләү тәртибе турында» Татарстан Республикасы Законының 3 статьясына үзгәреш кертү хакында» 445-5 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында**

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә:**

Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Социаль сәясәт комитеты тарафыннан кертелгән «Татарстан Республикасында җан башына һәм халыкның төп социаль-демографик төркемнәре буенча яшәү минимумы күләмен билгеләү тәртибе турында» Татарстан Республикасы Законының 3 статьясына үзгәреш кертү хакында» 445-5 номерлы Татарстан Республикасы законы проектын беренче укылышта кабул итәргә.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе**
**Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2018 елның 25 апреле
№ 2278-V ДС

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

**313. «Татарстан Республикасында җан башына һәм халыкның төп социаль-демографик төркемнәре буенча яшәү минимумы күләмен билгеләү тәртибе турында» Татарстан Республикасы Законының 3 статьясына үзгәреш кертү хакында» Татарстан Республикасы законы турында (445-5 номерлы проект)**

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә:**

1. «Татарстан Республикасында җан башына һәм халыкның төп социаль-демографик төркемнәре буенча яшәү минимумы күләмен билгеләү тәртибе турында» Татарстан Республикасы

Законының 3 статьясына үзгәреш кертү хакында» Татарстан Республикасы законын (445-5 номерлы проект) кабул итәргә.

2. Күрсәтелгән законны Татарстан Республикасы Президентына җибәрергә.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе**
**Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2018 елның 25 апреле
№ 2279-V ДС

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

### 314. «Татарстан Республикасында мәдәни мирас объектлары турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 447-5 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә:**

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан кертелгән «Татарстан Республикасында мәдәни мирас объектлары турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 447-5 номерлы Татарстан Республикасы законы проектын беренче укылышта кабул итәргә.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе**
**Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2018 елның 25 апреле
№ 2280-V ДС



## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

### 315. «Татарстан Республикасында мәдәни мирас объектлары турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законы турында (447-5 номерлы проект)

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә:**

1. «Татарстан Республикасында мәдәни мирас объектлары турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законын (447-5 номерлы проект) кабул итәргә.

2. Күрсәтелгән законны Татарстан Республикасы Президентына җибәрергә.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе**
**Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2018 елның 25 апреле
№ 2281-V ДС

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

### 316. Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Дәүләт корылышы һәм җирле үзидарә комитетының 2014 елның октябреннән 2018 елның апреленә кадәрге эше турында хисап хакында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә:**

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Дәүләт корылышы һәм җирле үзидарә комитетының 2014 елның октябреннән 2018 елның апреленә кадәрге эше турында хисапны игътибарга алырга.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе**
**Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2018 елның 25 апреле
№ 2282-V ДС

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

### 317. Табигатьтән файдалану өлкәсендә федераль күзәтчелек хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсе эшчәнлеге турында мәгълүмат хакында

Табигатьтән файдалану өлкәсендә федераль күзәтчелек хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсе җитәкчесе Ф.Ю. Хәйретдиновның Табигатьтән файдалану өлкәсендә федераль күзәтчелек хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсе эшчәнлеге турында мәгълүматын тыңлап, Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә:**

Табигатьтән файдалану өлкәсендә федераль күзәтчелек хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсе эшчәнлеге турында мәгълүматны игътибарга алырга.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе**
**Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2018 елның 25 апреле
№ 2283-V ДС

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

### 318. «Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 8 статьясына үзгәреш кертү турында» 67151-7 номерлы федераль закон проекты текстын үзгәртү хакында

Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасы Регламентының 112 статьясындагы алтынчы өлеше нигезендә Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә:**

1. «Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 8 статьясына үзгәреш кертү турында» 67151-7 номерлы федераль закон проектының Татарстан Республикасы Дәүләт Советы тарафыннан закон чыгару инициативасы тәртибендә Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасына кертелгән текстын, аны яңа редакциядә бәян итеп, үзгәртергә.



2. Әлеге карарны Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасы Рәисе В.В. Володинга җибәрергә.
3. Әлеге карар кабул ителгән көненнән үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе**
**Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2018 елның 25 апреле
№ 2284-V ДС

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

### 319. «Әйләнә-тирә мохитне саклау турында» Федераль законга үзгәрешләр кертү хакында» федераль закон проектын Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасына кертү буенча Ленинград өлкәсе Закон чыгару Собраниесенең закон чыгару инициативасы турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә:**

1. «Әйләнә-тирә мохитне саклау турында» Федераль законга үзгәрешләр кертү хакында» федераль закон проектын Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасына кертү буенча Ленинград өлкәсе Закон чыгару Собраниесенең закон чыгару инициативасын хупларга.
2. Әлеге карарны Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасына һәм Ленинград өлкәсе Закон чыгару Собраниесенә җибәрергә.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе**
**Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2018 елның 25 апреле
№ 2285-V ДС

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

**320. «Россия Федерациясе Салым кодексының икенче өлешенә килештерү процедураларын камилләштерүгә бәйле рәвештә үзгәрешләр кертү турында» 421494-7 номерлы федераль закон проекты хакында (дәүләт пошлинасын кире кайтару турында)**

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә:**

1. «Россия Федерациясе Салым кодексының икенче өлешенә килештерү процедураларын камилләштерүгә бәйле рәвештә үзгәрешләр кертү турында» 421494-7 номерлы федераль закон проектын (дәүләт пошлинасын кире кайтару турында) хупларга.

2. Әлеге карарны Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасына җибәрергә.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе**
**Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2018 елның 25 апреле
№ 2286-V ДС

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

**321. «Вакытны билгеләү турында» Федераль законга үзгәрешләр кертү хакында» 383137-7 номерлы федераль закон проекты турында (Россия Федерациясе территориясендә вакытны билгеләүне үзгәртү хакында)**

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә:**

1. «Вакытны билгеләү турында» Федераль законга үзгәрешләр кертү хакында» 383137-7 номерлы федераль закон проектын (Россия Федерациясе территориясендә вакытны билгеләүне үзгәртү хакында) хупларга.

2. Әлеге карарны Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасына җибәрергә.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе**
**Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2018 елның 25 апреле
№ 2287-V ДС



ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

**322. «Балаларны аларның сәламәтлегенә һәм үсешенә зыян китерә торган мәгълүматтан саклау турында» Федераль законга һәм «Китапханә эше турында» Федераль законның 7 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» 424390-7 номерлы федераль закон проекты турында (балалар өчен тыелган мәгълүмат продукциясен тарату өлешендә)**

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә:**

1. «Балаларны аларның сәламәтлегенә һәм үсешенә зыян китерә торган мәгълүматтан саклау турында» Федераль законга һәм «Китапханә эше турында» Федераль законның 7 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» 424390-7 номерлы федераль закон проектын (балалар өчен тыелган мәгълүмат продукциясен тарату өлешендә) хупларга.

2. Әлеге карарны Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасына җибәрергә.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе**
**Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2018 елның 25 апреле
№ 2288-V ДС

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

**323. «Россия Федерациясе Торак кодексының 155 статьясына үзгәреш кертү турында» 395679-7 номерлы федераль закон проекты хакында (торак урын яшәү өчен яраксыз дип танылган очракта торак урыннарны яллаучыларны наем өчен түләүдән азат итү өлешендә)**

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә:**

1. «Россия Федерациясе Торак кодексының 155 статьясына үзгәреш кертү турында» 395679-7 номерлы федераль закон проектын (торак урын яшәү өчен яраксыз дип танылган очракта

торак урыннарны яллаучыларны наем өчен түләүдән азат итү өлешендә) хупларга.

2. Әлеге карарны Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасына җибәрергә.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе**
**Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2018 елның 25 апреле
№ 2289-V ДС

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

### 324. «Этил спиртын, алкогольле һәм спиртлы продукцияне җитештерүне һәм аларның әйләнешен дәүләт җайга салуы һәм алкогольле продукцияне куллануны (эчүне) чикләү турында» Федераль законга үзгәрешләр кертү хакында» 406404-7 номерлы федераль закон проекты турында (Россия Федерациясе субъектлары дәүләт хакимияте органнарына алкогольле продукцияне ваклап сатуны, шул исәптән җәмәгать туклануы хезмәтләрен күрсәткәндә, чикләү һәм тыю буенча өстәмә вәкаләтләр бирү өлешендә)

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә:**

